ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

6 декабрь, 2023 ел №28/10

Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11, 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2019 елның 7 октябрендәге 33/14, 2020 елның 6 февралендәге 36/8, 2021 елның 27 маендагы 7/10, 2023 елның 29 мартындагы 22/9 номерлы Карарлары редакциясендә) 7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ КЛАСС ЧИННАРЫ

15. Класс чиннары муниципаль хезмәткәрләргә бирелә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.

Вазыйфаи инструкция нигезендә йөкләнгән вазыйфаларны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәү муниципаль хезмәткәрнең эшчәнлеген бәяләү критерийлары булып тора.

16. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннарын бирү муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт уза торган җирле үзидарә органы җитәкчесе тәкъдиме буенча

Яр Чаллы шәһәре Хакименең хокукый акты белән башкарыла.

Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар барлык кирәкле документлар белән класс чинын бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

Муниципаль хезмәткәргә класс чинын бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе һәм кушымта итеп бирелә торган документлар исемлеге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, әлеге Нигезләмә нигезендә Яр Чаллы шәһәре Хакименең хокукый актлары белән билгеләнә.

Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирелгән көннән алып класс чины өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү билгеләнә.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев